# Ял сәгатьләрендә

### *Кыш бабай ясыйбыз*

**Кирәкле әйберләр:** кетчуп савыты,мех һәм синтепон кисәкләре, алсу тукыма, кызыл трикотаж кисәге, мамык, төсле кәгазь, ПВА җилеме, кайчы.

**1**. Кетчуп савытын әйбәтләп юып киптер. Алсу тукыма кисәгеннән түгәрәк кис һәм ПВА җилеме белән кетчуп савытына ябыштыр. Кызыл трикотаж кисәгенең кырыйларын борынга охшатып тегеп куй, эченә мамык тутыр, аны җилем ярдәмендә битнең уртасына урнаштыр.


**2**. Мех яки синтепоннан Кыш бабайның сакалына охшатып өчпочмак кис һәм борын астына ябыштырып куй. Аннары шул ук материалдан мыекларын да сакал өстенә беркет. Мыек һәм сакал арасына кызыл кәгазьдән авыз-иреннәр кисеп ябыштыр. Кара яки зәңгәр кәгазьне кисеп, борын өстенә күзләр, синтепоннан чәчләр яса.

**3**. Кетчуп савытының башына Кыш бабай башлыгының ак помпаның мех кисәгеннән ясап ябыштыр.

Шулай итеп, Кыш бабай әзер! Син аны чыршы астына куя аласың! Афәрин!



### *ӘДӘБИ КРОССВОРД*



**Сулдан уңга: 5. Г. Бәширов хикәясе. 6. М. Җәлилнең “Моабит дәфтәрләре”ндәге шигыре. 8. Г. Тукайның “Печән базары, яхүд яңа Кисекбаш” поэмасында телгә алынган күл. 9. Муса Җәлилнең беренче шигырьләр җыентыгы. 11. Спектакль пәрдәләре арасындагы тәнәфес. 13. Урыс былинасы герое. 17. А.Толстойның “Алтын ачкыч, яки Буратино маҗаралары” әкияте герое ... – Барабас. 18. “Маякчы кызы” повесте авторы. 19. Дөньяның ике кыйтгасына (Африка һәм Азия) урнашкан дәүләт. 20. Татарстанда нәшер ителә торган журнал.**

**Өстән аска: 1. Ф. Кәримнең 1944 елда язган шигыре. 2. Сука-сабан белән җир сөргәндә тар булып сузылган эз, ерма. 3. Г. Гобәйнең бер повесте персонажы. 4. Хатын-кызларның баш киеме. 7. Г. Камал комедиясе. 10. Г. Кандалый туган авыл. 12. Г. Исхакыйның “Җан Баевич” комедиясе героинясы. 14. Гомәр Бәшировның әдәби псевдонимы. 15. ХХ гасыр башында Казанда чыгучы газета. 16. Илдар Юзеевның “Авылым легендасы” поэмасы герое.**



### *Бәйрәм табынына*

**“Шатлык” салаты**

Салат катлы-катлы итеп ясала.

400 грамм пешкән тавык ите, 4 тозлы кыяр,
2 йомырка, 1 суган, 1 кишер, 100 грамм консервланган яшел борчак, 100 грамм каражимеш, тоз, майонез кирәк.

Иң элек тавык итен ваклап турарга кирәк. Аннан соң угычта уылган тозлы кыяр, вак итеп туралган суган, йомырка, яшел борчак,каражимеш салына.Катлам саен тоз сибелә һәм майонез сылана.

Тәмле булсын!

**Газетаны оештыручы һәм баш редактор:**
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Әхмәтгалиева Эльмира Алис кызы
**Редколлегия әгъзалары:** Зарипова Миләүшә Рафис кызы, Мифтахетдинова Фирдания Ансар кызы.
**Индекс-** 422020

**Адрес:** ТР, Арча муниципаль районы ,Яңа Кырлай авылы, Үзәк урам, 2 йорт.

# ЧИШМӘ БАШЫ

*“Туган телне сөючеләр”нең матбугат үзәге*

*Декабрь,2024*
*№ 1*



**Хөрмәтле коллегаларым !**

Яңа ел сәгате! Ул безне чиксез киләчәк белән тоташтыручы бер мизгел. Бер уйласаң, Иске ел киченнән Яңа ел таңына бер адым. Һәм менә шул бер адымда – әйтеп бетергесез өметләр белән тулы киләчәк. Әле дә шул өмет бар. Өмет белән тулы хисләрне дөньяга белдерү өчен туганнар,хезмәттәшләр, дуслар, якташлар,ватандашлар бар.

Сезне ихлас күңелдән Яңа ел бәйрәме белән котлыйм! 2024 нчы ел мәгариф тарихында ирешелгән яңа казанышлар, киләчәккә билгеләгән уй-хыялларыбызны тормышка ашыру мәшәкатьләре белән истә кала.Иң мөһиме- республикада һәм районда тынычлык, төрле милләтләр арасында татулык хөкем сөрсен. Яңа ел Республикабыз мәгарифен үстерүдә уңышлы гамәлләр,шатлыклы мизгелләр,киләчәккә өмет һәм ышаныч китерсен.Изге уй-ниятләрегез, хыялларыгыз чынга ашсын,яңа 2025 нче ел тынычлык, иминлек,яңа уңышлар,шатлык-сөенечләр генә алып килсен.Ихлас күңелдән ныклы сәламәтлек,шәхси бәхет,рухи күтәренкелек һәм күңел тынычлыгы телим.Тормыш дәфтәрегезгә бүгенге минутларда иң изге, хәерле теләкләр язылсын.

Г.Тукай исемендәге Яңа Кырлай урта мәктәбе җитәкчесе З.И.Хайруллина

**Хөрмәтле дуслар!**

Яңа ел! Бу сүзләрне ишетүгә безнең күз алдыбызга хуш исле зифа чыршы, мандарин тулы табын, ап-ак кар бөртекләре, җемелдәвек сихри утлар килеп баса.

Яңа ел диюгә, күңелдә үткәннәр белән хушлашу сагышы һәм өметле киләчәк белән кавышу шатлыгы уяна.

Яңа ел диюгә – уен-көлке, җыр-бию, Кыш бабай, Кар кызы күз алдына килә.

Яңа ел ул – дусларны, туганнарны бергә җыйган бәйрәм табыны.

Яңа ел – хыялларның канатланган чагы.

Яңа ел – үткәндә эшләгән эшләргә йомгак ясау чоры

Яңа еллар барыбызга да кояшлы көннәр,айлы төннәр,шатлык-куанычларга бай вакыйгалар,сәламәтлек,бәрәкәт алып килсен. Ышаныч, йөрәкнең серле бер почмагында сакланган өмет тормышка ашсын, бәхетебез мөлдерәмә тулып торсын. Шатлыклы хәбәрләр, бәхетле көннәр узган елдагын да күбрәк булсын, күңелсезлекләр иске елда калсын. Эшләребез уң,нәтиҗәле булсын, күңелебездәге мәрхәмәтлелек нуры җаныбызны тагын да ягымлы, матур итсен, ялкынландырып бизәсен.

# Изгелек кылырга ашык!

### Озын салкын кышларда ярдәм итик кошларга!

Кышын кошларга бик кыен. Кыска көннәрдә, азык табып, тамакларын туйдырырга да өлгермиләр, инде кич килеп житә. Бозлавык вакытларда аларга агач кәүсәсе буйлап ризык эзләве тагын да кыенлаша. Шулай итеп, бик суык көннәрдә күп кенә кошлар туңып үләләр. Моны ничек булдырмый калырга соң?Әлбәттә,жимлекләр ясап эләргә кирәк.
Безнең жимлекләрне кошлар инде күптән үз итте.Алар мәктәбебез янындагы агачларда көне буе канатлы дусларыбызны кунак итәләр.Ә без аларга көн саен жим:ипи катылары,ашлык салып торабыз.Кошлар исә безнең сыйны бик яратып ашыйлар,карап торырга ук күңелле.
Ашагыз,рәхәтләнеп сыйланыгыз,сез безгә бик кадерле!









# Мәктәп тормышы

Мәктәбебездә фән атналыклары башланып китте. 9 нчы декабрьдән 14 нче декабрьга кадәр математика, информатика һәм физика атналыгы үткәрелде.

Беренче көннең иртәсе атналыкны ачу тантанасы белән башланып китте. Атналык планына кертелгән һәр чарада укучылар актив катнаштылар.Класслар арасында ярышлар үткәрелде.Укучылар кызыклы математик биремнәр ,крассводлар, ребуслар чиштеләр.Атналык бик жанлы үтте.Ярышта жиңгән укучыларга грамоталар тапшырылды.





## Яңа елга матур күрсәткечләр

| № | Предмет | Укучының фамилиясе, исеме | Класс | Урын | Укытучысы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Рус теле | Ганеева Алина | 9 | призер | Гайфуллина Л. |
| | | Гайфуллина Рузия | 11 | победитель | Гайфуллина Л. |
| | | Шакирова Алсу | 11 | призер | Гайфуллина Л. |
| 2 | Литература | Гайфуллина Рузия | 11 | победитель | Гайфуллина Л. |
| 3 | Английский язык | Шакиров Инсаф | 4 | призер | Рахимова Р. |
| 4 | Хезмәт | Сабиров Рәдис | 8 | призер | Солтанов И. |
| 5 | Экология | Агеева Катя | 8 | призер | Шакирова К. |
| 6 | География | Фасхутдинов Илшат | 10 | призер | Солтанов И. |
| 7 | Биология | Гайфуллина Рузия | 11 | призер | Мифтахова Г. |
| | | Галимзянов Ильназ | 9 | призер | Шакирова К. |
| 8 | Математика | Ганеева Алина | 9 | призер | Ганеев И. |
| 9 | Җәмгыять белеме | Ганеева Алина | 9 | призер | Шигапова Г. |
| 10 | Хокук нигезләре | Агеева Катя | 8 | призер | Шигапова Г. |
| | | Сафиуллин Раил | 9 | призер | Шигапова Г. |
| 11 | Тарих | Хайдарова Илюза | 8 | призер | Шигапова Г. |
| | | Галимуллина Ландыш | 9 | призер | Шигапова Г. |
| 12 | Физкультура | Агеева Катя | 8 | призер | Шакиров И. |
| 13 | ОБЗР | Фасхутдинов Илшат | 10 | призер | Шакиров И. |
| | | Мустафин Камил | 3 | призер | Зиятова Д. |
| 14 | Татартеле | Хайдарова Илюза | 8 | призер | Зарипова М. |
| | | Ганеева Алина | 9 | призер | Зарипова М. |
| | | Закирова Зухра | 6 | призер | Ахметгалиева Э. |
| | | Шакирова Алсу | 11 | призер | Ахметгалиева Э. |
| 15 | Татар әдәбияты | Хайдарова Илюза | 8 | призер | Зарипова М. |
| | | Ганеева Алина | 9 | призер | Зарипова М. |
| | | Галимзянов Ильназ | 9 | призер | Зарипова М. |
| Барлыгы | | 3- жиңүче , 24 - призер | | | |

# Батырларның даны мәңгелек

### Истәлекле очрашу

16 нчы декабрь көнне мәктәптә зур бәйрәм булып узды.

Безнең яшь гражданнар, 8-9 нчы сыйныф укучыларына бәйрәмнең хөрмәтле кунаклары: кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе Надия Мифтахетдинова, Арча районының Беренчеләр Хәрәкәте Җирле бүлеге Советының рәисе Лия Ильина, Әфган сугышы һәм махсус хәрби операциядә катнашучы, мәктәбебез укучысы Фоат Абдуллин һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларга гуманитар ярдәм күрсәтүче һәм аны адресатларына илтеп җиткерүче, шулай ук мәктәбебез укучысы Илнур Яруллин - кулыннан Россия Федерациясе гражданины паспорты һәм Беренчеләр Хәрәкәтеннән бүләкләр алу бәхете насыйп булды.





### 9 декабрь - "Геройлар көне"

9 декабрьдә Россиядә Ватан Геройлары Көне билгеләп үтелә. Бу көн бәйрәм буларак чагыштырмача күптән түгел, 2007 нче елда гына, билгеләнеп үтә башласа да, аның тамырлары тирәндә ята. Геройлык сугыш кырында гына түгел, тыныч вакытта да эшләнергә мөмкин. Укучылар белән зур хезмәт һәм үз-үзеңне корбан итү бәрабәренә эшләнгән кешелекнең космоска беренче адымнары, Юрий Гагарин, С.П.Королёв, Алексей Леонов батырлыклары турында сөйләшергә мөмкин. Шулай ук тыныч вакытта эшләнгән геройлык мисаллары булып, 2022 елда пандемия башланганда безнең врачларның батырлыклары, пассажир самолётын утыртып, 233 гомерне саклап калган очучы Дамир Юсуповның гамәлләре тора. Ватан геройлары – үз Илләрен яратучы, Ватаннары өчен көрәшүче һәм хезмәт итүче фидакарь һәм батыр кешеләр. Герой сыйфатлары – профессиональлек һәм дисциплина, кыюлык һәм батырлык, үз-үзеңне корбан итү һәм башкалар язмышы өчен җаваплы булу. Махсус хәрби операциядә катнашучылар – илебезнең киләчәген саклаучылар. Геройларга карата хөрмәт күрсәтү, кыюлык, тәвәккәллек, батырлык кебек илебезнең җаваплы гражданинына хас ихтыяр сыйфатларын үзеңдә булдырырга омтылу. Батырлык, фидакарьлек, туган илне ярату һәм җаваплылык хисе - һәр чорның геройларына хас сыйфатлар.



# Мәктәп тормышы

Мәктәп тормышы

Арча районында үткән "Яңарыш" агрофирмасы җитәкчесе Садыйков Илгизәр Минневәлиевич призына үткәрелгән көрәш ярышларында җиңү яулаган егетләребезне котлыйбыз.

Минуллин Раяз - 1 урын (7класс)
Хасанов Данир - 3 урын (6класс)
Ахметгалиев Данияр - 3 урын (4класс)

Тренерлары Саляхов Марат Радик улына һәм егетләргә киләчәктә дә уңышлар телибез.









# Сәламәт булыйк!

## Ничек авырмыйча калырга?!

**Урамда – чын кыш. Салкыны да, кары да бар – күңелле. Тик һава температурасының үзгәреп торуы гына тирән сулыш юллары вируслы инфекциясе белән авыручылар санын арттыра. Игътибар итсәгез, соңгы көннәрдә туңып, төчкереп-ютәлләп йөрүчеләр ешрак күренә. Авырый башлагач, тизрәк дәвалану хакында уйлыйбыз. Чынлыкта исә организмны авырмас өчен алдан ук әзерләргә кирәк.**

### *Сәламәтлекне ныгыту*

Чыныгу – кискен респиратор инфекцияләрне профилактикалауда аеруча зур әһәмияткә ия. Күбрәк саф һавада йөрергә, бүлмәне ешрак җилләтергә, көндәлек режимны үтәргә, дөрес тукланырга һәм температурага туры килерлек кием киярgә кирәк.

Аскорбин кислотасы (С витамины) организм өчен аеруча әһәмиятле. Ул организмның инфекциягә каршы торучанлыгын, канның оешу сәләтен арттыра, углеводлар әйләнешен яхшырта. С витамины аеруча тозлы кәбестә суында, лимон, киви, мандарин, апельсин һәм грейпфрутта күп. Көнбагыш мае кушып ясалган кәбестә салаты шулай ук витамин һәм микроэлементларга бай.

### *Кисәткеч чаралар*

Сарымсак. Грипп һәм сулыш юлларындагы вируслы инфекциягә каршы элек-электән бик әйбәт дәва буларак кулланылып килә. Андагы фитонцидлар бактерияләрне үтерү сәләтенә ия. Шул фитонцид дигән матдә аркасында сарымсак көчле искә ия дә инде.Гриптан саклану өчен 50-100 г сарымсак ваклап, шул ботканы тәлинкәгә салыгыз һәм, аның янына басып, 10-15 минут буе тирән итеп сулап торыгыз. Кыш көне мондый чараны авырулардан саклану өчен көн саен кулланырга кирәк.

2-3 сарымсак тешен угычта уып, аны шулкадәр үк ба белән катнаштырыгыз һәм савытны икенче сулы савытк куеп ут өстенә утыртып, 36-40 градуска кадә җылытыгыз. Әзер катнашма пыяла савытта саклана Грипп кебек вируслы авырулардан саклану өчен ан көненә ике тапкыр берәр чәй кашыгы күләмендә (җылы су белән йотып җибәреп) 3-7 көн кулланырга киңә ителә

Суган, сарымсакның тамыр ягын кисеп, борынның әлебер, әле икенче тишеге белән иснәргә. Грипп көчәйгән чакта моны иртән һәм кичен эшләргә кирәк.һәр көнне бер аш кашыгы ваклап тураган суганны бер аш кашыгы каймакка салып, көндезге аш вакытында ашарга.

Грипп киң таралган көннәрдә көн саен ике-өч тырнак сарымсак ашарга.

### *Кискен респиратор авыруларны һәм кисәтү һәм дәвалау өчен халык медицинасы рецептлары*

.. Вак угычта кишер кырыгыз. Сыгып алынган кишер суына 1:1 исәбеннән зәйтүн мае һәм 2-3 тамчы сарымсак согы кушыгыз. Барлыкка килгән катнашманы борынга көненә өч тапкыр икешәр тамчы тамызырга.

Дүрт аш калагы вак итеп туралган суганга ярты стакан җылы кайнаган су салырга, бер чәй калагы бал кушып, утыз минут тотарга. Катнашманы көненә өч тапкыр икешәр тамчы борынга салырга.

Ике чәй калагы бал һәм ике чәй калагы чөгендер суын кушып болгатырга. Көненә өч тапкыр борынга өчәр тамчы салырга.Нарат яки чыршы ылысларын җыеп (аларны җәйдә үк хәстәрләп куйсаң да була), 40-50 данә энәләрен әзерләгез. Эмаль кружкада яки кечкенә эмаль кәстрүлдә 250 г су кайнатыгыз һәм аз-азлап кына шуңа энәләрне салыгыз. Әгәр ылысны яңа җыйган булсагыз, 20 минут кайнатырга кирәк, ә инде җәй һәм яз айларында җыеп хәстәрләнгән булса — 40 минут. Аннары кайнатманы сөзеп алырга (әйткәндәй, ылысларны башта ук марляга урап салырга да мөмкин — сөзеп торасы да булмый). Менә шушы порцияне көн дәвамында ашалган азыклар белән бергә 2-3 тапкыр эчәргә кирәк. Тәмен үзгәртер өчен бал яки шикәр кушарга да мөмкин. Искәрмә: җәй яки яз көннәрендә җыйган ылысларны суыткычның туңдыру камерасында (кечкенә ботаклар белән булса, яхшырак) сакларга кирәк.

Сәламәт булыгыз!





## Яңа ел могҗизалары

Яңа ел- һәр кешенең көтеп алган зур бәйрәме. Яңа ел – балачак бәйрәме, могҗизалар чоры. Аны күңелле итеп уздыру өчен эзлекле, ныклы әзерлек таләп ителә. Районыбыз күптән Яңа ел мохитенә чума башлады инде. Алда исә олыларны да, балаларны да күпсанлы бәйрәм чаралары көтә. Алар декабрь уртасыннан башланып, гыйнвардагы озын ялларны тулысынча колачлаячак.

Яңа ел алды мәшәкатьләренең иң мөһиме – кар сыннары ясау. Иң беренче мәктәп яны әйләнәсен өмә ясап, дәррәү кубып кар эвәләп төрле сыннар белән бизәдек.

Укучылар, укытучылар һәм әти-әниләр көче белән җан өрелгән бу сыннарга һәркем исе китеп, сокланып карый. Олыларга– мәшәкать булса да, сабыйларга зур сөенеч өсти, язга кадәр карашны иркәләп тора бу әкияти дөнья.









# Белем дөньясында

Һәр кеше кече яшьтән үк үз хокукларын белергә тиеш. Шул уңайдан Арча районында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе Мифтахетдинова Надия Равил кызы 8-10 класс укучыларына кеше хокуклары буенча дәрес уздырды. Соңыннан укучыларның алган белемнәрен тикшерү максатыннан викторина үткәрде. Надия Равил кызы укучыларның белеменнән канәгать калуын әйтте, аларга зур уңышлар һәм киләчәктә үз хокукларын якларлык гражданнар булып үсүләрен теләде.











Яңа елга яңа юлдан,
Нык басып бердәм керик.
Иң изге ,саф теләкләрне
Бер-беребезгә телик.
Яңа бәхет, зур уңышлар
Алып килсен Яңа ел.



# Яңа елны көтә йөрәкләр

***Кил, Яңа ел!***

Җир өстенә карлар ява,
Нинди сихри тамаша.
Әйтерсең лә һәр бөртеге
Бер-берсенә караша.
Бу тамашаның хуҗасы-
Яраткан Кыш бабабыз.
Ак карларга чума-чума
Яңа елга барабыз.
Кил, Яңа ел, шатлыкларны,
Сөенеч,бәхет алып.
Барлык борчу һәм кайгылар
Югалсын артта калып.

***5 нчы класс укучысы***

***Яңа ел теләкләре***

Яңа елда һәркем нидер көтә,
Шатлык, бәхет, сөю өмет итә.
Җирдә бәхет һәрчак ныклы булсын,
Котлы булсын бу ел, котлы булсын!
Декабрь бураннары алып килгән
Яңа еллар белән!
Бәйрәмнәр мөбәрәк, ризык тулы өстәлләр
түгәрәк,
күңелле, куанычлы булсын!
Эшләр гөрләп барсын,
Күңелләрдә мәрхәмәтлелек нуры чәчәк атсын!
Җаннарны тагын да ягымлы, матур итсен,
Ялкынландырып бизәсен!
Бусагалардан караңгылык, салкынлык,
Хәвеф-хәтәр атлап кермәсен, бәла-каза
йөрмәсен!

**6 нчы класс укучысы**

**Яңа елга теләкләр**

Җир өстенә ап-ак карлар ява, күңелләргә шатлык иңә. Әйтерсең лә Иске ел безгә үзенең соңгы бүләген тапшырырга ашыга. Дусларым, табигатьнең бу олы бүләген куанып кабул итик. Ап-ак карлар Җир-ананы караңгылык, салкынлык, бәла-казалардан сакласын! Кешелекне начарлыктан , күнче хисләрдән араласын ! Күңелләребез кардай чиста , кылган гамәлләребез изгелектән торса гына күркәм яши алырбыз.
Ап-ак карларга уралып, кышкы кичтә җемелдәгән йолдызлары белән Яңа ел килә. Күңел нииндидер могҗиза көтә. Яңа елның аткан һәрбер таңы алсу булсын иде! Дуслык, туганлыкны тоеп, уңыш, шатлыкларга күмелеп яшик. Куанычлы мизгелләр күп булсын ! Еллар матур килсен, илдә тынычлык булсын, һәрбер гаиләгә бәхет алып килсен. Яңа елга беренче адым изгелек булсын. !

Ак карларда ак бәхетләр
Энҗеләрдәй сибелсен!
Өр-Яңа ел котлы булсын
Шатлыклардан чигелсен

**Якынлашып килүче Яңа ел белән сезне!**
**7 нче класс укучылары**

# Шигъри Мизгеллэр

**Ап-ак дөнья буйлап ялгыз атлыйм ...**

Җир өстенә күбәләк карлар ява,
Аклык өстәп кеше күңеленә.
Сагышларның барсын оныттырып,
Матур уйлар килә күңелгә.

Җемелдәшә күзләр кысып ак энҗеләр,
Күзең камашырлык матурлык.
Юктыр сыман җир йөзендә берни
Шушы матурлыкка торырлык.

Ап-ак дөнья буйлап ялгыз атлыйм,
Бу аклыкның чиге юк сыман.
Уйларымда бергә булган чаклар,
Синең белән бар дөньям тулган.

***Зиятова Дилбәр башлангыч класс укытучысы***



## Минем авылым.

Минем авылым Тукай-Кырлай,
Матур җиргә урнашкан.
Аны чолгаган урманнар
Маригача тоташкан.
Ул урманнар - тылсымлы,
Керсәң, югалып каласың,
Эчкәрәк үтсәң Тукайның
Шүрәлесенә юлыгасың.
Ул урманда бик күп үсә
Каен, чыршы, усак, нарат,
Әдип әйткәндәй буладыр,
Хәл җыеп, күккә карап.
Урман бит ул хәзинә,
Бар нәрсәне дә бирә,
Иренмәсәң, җый гына:
Җиләк, чикләвек, гөмбә.
Авылыбызның уртасыннан
Ия елгасы ага,
Җәй көне шул елгада
Коена бала-чага.
Җәйләр җиткәч, авылыбызда
Гөрли Сабантуйлары,
Шау-гөр килә киң болыннар,
Авыл һәм су буйлары.
Авылымның киләчәген
Бик матур итеп күрәм,
Мин горур һәм бик бәхетле
Шунда яшәвем белән.

***9 нчы сыйныф укучысы Галимҗанов Илназ***

## Тукай абый мирасы.

Тукай калдырган мирасны
Белү безгә бик зарур,
Туган телне саклауда
Аның өлеше бик зур.
Ул мирасны өйрәнәләр
Чуаш, мари һәм кыргыз,
Чит илдә дә күп безнең
Теләктәш дусларыбыз.
Әйдәгез, дуслар, һәммәбез
Китап алыйк кулларга,
Шул мирасны саклап, илтик
Киләчәк буыннарга!

***9 нчы сыйныф укучысы Галимҗанов Илназ Илдар улы***



# Кышкы бизәкләр


### Мәкальләр

- Кыш җитсә, буран туздырыр;
  Җәй җитсә, кояш кыздырыр.
- Кышка каршы тиен дә запас җыя.
- Кышкы кар – көзге икмәк.
- Кары калын кышның үләне калын булыр.
- Каты суык кардан яман.

## Газиз татар телем!

Һәркемнең бар газиз туган теле,
Балдай татлы, яздай ягымлы,
Җир астыннан чыккан чишмә суы кебек
Саф сүзләре аның шифалы.
Йомшак итеп, кайсы телдә тагын
Әнкәй дәшә алыр иркәләп?
"Балакаем бит син, йолдызым"- дип,
Күңелемә нурлар сипкәләп.
Ә этием миңа "батырым" ди,
"Лачыным" ди шулай кадерләп.
Күңелем булып, канатланам мин дә,
Үсеп китәм хәтта тизерәк.
Җәйге таңда җылы кояш нуры
Битләремне гүя иркәли,
Ул да минем туган телем кебек
Бар җиһанга яктылыгын сирпи.
Туган телем ! Нәфис татар теле!
Нәзакәтле дә син, горур да,
Кар бөртеге кебек шаян да син,
Алтын –көмешләрдәй затлы да.
Киң күңелле газиз татар теле
Чит-ят итми башка телләрне,
Дус-тату ул урыс, мари белән,
Шулай яшәүләре мәгънәле.
"Тормыш яме нидә?" – диючегә
Әйтер идем, милләтеңне тану,
Ватаныңны саклау, телне белү,
Шушы байлыгыңа риза булу.
Татар авылында гомер итәм,
Горурланып атлыйм урамнан,
Татар җыры, татар көен тыңлыйм,
Милли бәйрәмнәргә сокланам.
Җир йөзендә һәрбер кешегә дә,
Үзенең туган теле кадерле,
Ә мин – татар, татар булуыма,
Татарстаныма рәхмәтле.

***9 нчы сыйныф укучысы Галимҗанов Илназ Илдар улы***



***Татар халкы табигатьтәге үзгәрешләргә элек-электән игътибар иткән һәм алдагы көн, ай һәм, хәтта, елда һава торышы нинди булачагын алдан сыный торган булган...***

– Болытлар түбәннән килсә, каты суыкны көт.
– Кыш көне болытлар юлланып торса, җәй җылы булыр.
– Кышның төньяк бураннары ашлык җыйганда яңгыр китерер.
– Көн озая башлагач, гыйнвар башында, бәс төшсә, җәй ашлык чәчкәндә чык булыр.
– Кыш бәс, томан булса, җәй иген уңа.



**– Кыш көне яңгыр яуса, икмәк булыр.**
**– Кыш сыкы булса, җәй алма була.**
**– Кыш томан булса, җәй юкәдә бал була.**
**– Әгәр кар вак кына бөртекле, сирәк кенә төшкәләсә, бик озак суык булыр.**
**– Кыш кар күп булса, җәй яңгырлы булыр.**
**– Гыйнвар унында бәс тотса, җәй яңгырлы килә.**
**– Әгәр елга суы боз өстенә чыкса, көн җылытыр.**
**– Тоз юеш булса, кыш көне җепшек була.**
**– Моржадан чыккан төтен туры булып өскә менсә, көн аяза, суыта. Әгәр төтен җиргә ятса, көн җылыта.**
**– Утын сызгырса, көн суытыр.**
**– Тау башларында кар күп булса, җиләк күп булыр.**